ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
“ ГАДЕЛША АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

"24 " сентябрь 2018 г. № 56/1

Чистай муниципаль районы
Гаделша авыл җирлеге
территориясендә гражданнарга
үзара салым кертү һәм аның акчасын
файдалану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Жирле референдум турында” 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чистай муниципаль районы “Гаделша авыл җирлеге” Уставының 11 статьясы нигезендә, Гаделша авыл җирлеге Советының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 55/1 номерлы карары, Гаделша авыл җирлеге Башкарма комитетының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 13 номерлы карары белән, Гаделша муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым салуны кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә ризамы :

-АРС-18 янгын сүндерү машинасы өчен бина төзүгә (проект документлары әзерләүгә, җир участогы бүлеп алырга);

- Гаделша, Дүрт Өйле һәм Чирүле Шонталысы авыллары эчендәге юлларны төзекләндерүгә (чокырларны тигезләү, щебенка сатып алу һәм җәю,грейдер белән тигезләү);

- Гаделша, Дүрт Өйле һәм Чирүле Шонталысы авылларындагы зиратларга чүп контейнерлары сатып алу һәм урнаштыруга;

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең халык күпләп җыела торган урыннарга, мәгълүмат стендлары һәм такталарына урнаштырырга.

Гаделша авыл җирлеге
башлыгы И.А.Нуретдинов